# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **25.11.2023 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чубар- Абдул авыл җирлеге составына кергән
Чубар Абдул авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 25 нояберендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2024 елда, Чубар –Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам яктырту челтәрләрен урнаштыру (светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру)
- авыл мәдәният йорты территориясен төзекләндерү (авыл мәдәният йорты территориясен һәм Бөек Ватан сугышы һәйкәлен коймасын ясау һәм урнаштыру)
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(грейдер белән юлларны тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү).

«Әйе» «Юк».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 237 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 154 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 154 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; җыенда катнашучы 0 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге составына керүче Чубар-Абдул авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2024 елда, Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан

сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам яктырту челтәрләрен урнаштыру (светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру)
- авыл мәдәният йорты территориясен төзекләндерү (авыл мәдәният йорты территориясен һәм Бөек Ватан сугышы һәйкәлен коймасын ясау һәм урнаштыру)
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(грейдер белән юлларны тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү) - кабул ителгән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 85 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов